ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Школьная, д.17, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 17 йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№9** **«05» февраля 2026 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 23 декабрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең балалар уен һәм спорт мәйданчыкларында балалар мәйданчыкларын, уен һәм спорт җиһазларын тоту һәм эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау, җиһазларның техник торышын һәм имин эксплуатациясен тикшереп торуны оештыру турында»гы 19 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 23 декабрендәге 19 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең балалар уен һәм спорт мәйданчыкларында балалар мәйданчыкларын, уен һәм спорт җиһазларын тоту һәм эксплуатацияләү, җиһазларның техник составын һәм куркынычсыз эксплуатациясен тикшереп торуны оештыру кагыйдәләре”нә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 4.2 пунктындагы 3 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Функциональ карау җайланманың төзеклеген һәм тотрыклылыгын тикшерү, җайланма конструкциясе элементларының тузганлыгын ачыклау максатында җентекле караудан гыйбарәт. Тикшерүне җитештерүче инструкциясе нигезендә өч айга бер тапкыр үткәрәләр. Җиһазларның яшерен, авыр үтеп керә торган элементларына аерым игътибар бирәләр.»

"Функциональ карау.

Функциональ карау җайланманың төзеклеген һәм тотрыклылыгын тикшерү, җайланма конструкциясе элементларының тузганлыгын ачыклау максатында җентекле караудан гыйбарәт. Тикшерүне җитештерүче инструкциясе нигезендә өч айга бер тапкыр үткәрәләр. Җиһазларның яшерен, авыр үтеп керә торган элементларына аерым игътибар бирәләр.

Функциональ карау җайланманың яисә уен мәйданчыгының функциональ төзексезлегенә (шул исәптән җайланманың шыгырдавы, терәкләрнең хәрәкәтчәнлеге, тотып торучы элементларның кыршылуы, өслек чокырлары) карата җайланмадан файдаланучы затларның шикаятьләре һәм гаризалары кергәндә дә үткәрелә.

Визуаль һәм функциональ караулар барышында:

- уен мәйданчыгы һәм җиһазлар өслегенең чисталыгы һәм тышкы күренеше;
- җайланма өлешләреннән уен мәйданчыгы өслегенә кадәр араны саклау;
- фундаментларның чыгып торган өлешләре булу;
- җиһаз элементларының җитешсезлекләре/төзексезлекләре булу;
- җиһазларның детальләре булмау;
- җиһазларның хәрәкәтчән өлешләре артык тузган;
- җиһазларның структур бөтенлеге» тикшерелә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина